Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең
Зур Лызи 1 өлеше авылында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» март, 2024 ел. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Зур Лызи 1 нче өлешендәге торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 2023 елның 25 ноябрендә Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлегенең Зур Лызи 1 нче өлешендәге торак пунктында гражданнар җыелышы №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче пункт түбәндәгечә расларга:

«2. Алынган акчаны түбәндәге эшне башкарып җирле әһәмияттәге проблемаларны чишү өчен кулланырга:

- җир асты суларының табигый чыганакларын (чишмәләрне) яхшырту (Зур Лызи 1 өлеш авылында чишмәгә юл төзеп чишмә суы белән тәэмин итү);

- торак пункт территориясен яхшырту (балалар һәм спорт мәйданчыкларын һәм Зур Лызи 1 өлеш авылы торак пунктын ремонтлау һәм төзекләндерү).

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов